**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 28 август № 631

г. Казань

Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләргә өстәмә һөнәри белем бирүне оештыруның үрнәк регламентын раслау турында

Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең өстәмә һөнәри белем алу системасын камилләштерү максатларында һәм «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 ел, 27 июль, ФЗ-79 нчы Федераль закон, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 ел, 2 март, ФЗ-25 нче Федераль закон, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 ел, 29 декабрь, ФЗ-273 нче Федераль закон, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 ел, 16 гыйнвар, ТРЗ-3 нче Татарстан Республикасы Законы, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләргә өстәмә һөнәри белем бирүне оештыруның үрнәк регламентын (алга таба – Регламент) расларга.

2. Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарына, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләрен өстәмә һөнәри белем бирү программалары буенча укытуны оештырганда, Регламентка таянып эш итәргә, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башка органнарына шуны тәкъдим итәргә.

3. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрне өстәмә һөнәри белем бирү программалары буенча укытуны оештырганда, Регламенттан файдаланырга тәкъдим итәргә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Югары, урта һөнәр белеме бирү һәм фән бүлегенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\631.doc